**ГЛАВА**
**Русско-Ошнякского**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422642, с. Русский Ошняк,
ул. Профсоюзная, дом 7а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422642, Рус Әшнәге,
Профсоюз урамы, 7а нче йорт,

Тел.: (84361) 24643, факс: (84361) 24643, e-mail:Rosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**08 ноябрь 2021 ел** **Рус Әшнәге ав** **№ 4**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын 2021 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- гидрант сатып алу һәм урнаштыру;
- Рус Әшнәге авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Рус Әшнәге авылы урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);

- Рус Әшнәге авылы урамнарына энергияне саклый торган лампалар сатып алу;
- Рус Әшнәге авылы урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;
- Рус Әшнәге авылының су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәг авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда кабул ителү белән 3 көн эчендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге
Башлыгы В.Х.Хаҗиев